Бәйрәмова, Ф.  "Сатмадым да, сатылмадым да" / Ф. Бәйрәмова; [әңгәмәдәш] А. Гайнуллина // Акчарлак. – 2024. – №14 (10 апрель). – Б. 2-3, 13.

**Фәүзия ханым Бәйрәмова редакциябезгә: "Гадәттә, журналистлар белән телефон аша гына эшлим. Габделфәтне аеруча хөрмәт итәм, бәхеткә, җае да туры килде бит менә", – дип елмаеп килеп керде. Янәшәсендә – тормыш иптәше, тәрәге, фикердәше Хөсәен әфәнде Аймалетдинов. Чаллыдан Түбән Новгородка китеп барулары иде.**



# Фәүзия Бәйрәмова: "Сатмадым да, сатылмадым да"



Фәүзия ханым тормыш иптәше Хөсәен Аймалетдинов белән

**– Фәүзия апа, сез Казанга архивлар тапшырырга киләм, дигән идегез. Нинди архивлар турында сүз бара?**

– Соңгы ике елда үземнең архивларымны Казанга тапшыра башладым. Кульязмаларымны, әдәби документаль әсәрләргә бәйле материалларны, хатларны Кремльдәге мирасханәгә тапшырдым. Дәүләт архивына 30 еллык милли хәрәкәткә бәйле документларны бирдем. Бу – милләтнең документлары бит, минеке түгел. Җавап килде: миннән 3 мең документ алганнар, шуның 1 мең данәсен гомерлеккә сакларга салып куйганнар. Миңа берәр хәл булса, милләт байлыгы, тарихи документлар югалмасын, дидем. Еллар үткәч, бу архивлар язучыларга, тарихчыларга, фәнни хезмәтләр язарга кирәк булачак. Безнең нинди идеяләр белән янып йөрүебез, нәрсә өчен борчылуыбыз кызыксындырыр бит аларны. Әйтик, 35 ел элек без Татарстан суверен булсын дип борчылдык. Татарстанда татар мәктәпләре, мәчетләр булсын дип тырыштык. Аңа кадәр Казанда бары бер генә татар мәктәбе һәм бер Мәрҗани мәчете генә бар иде. Милли университет кына ачтырып булмады. Ачтык без аны, анда профессорлар, укытучылар ике елдан артык бушка эшләдек. Алты факультет бар иде, 800ләп студент. Бинабыз булмады. Суверенитетны алдык, әмма бүген ул да юк.

**– Хезмәтегезне бәяләүче, сезгә дәүләт бүләкләре бирүче, шушы архивлар өчен нинди дә булса түләү бармы?**

– Сеңлем, ни сөйлисең?.. Кабул иткәннәргә өчен рәхмәт. Сөенә-сөенә тапшырам, чөнки ул минеке түгел, ул – милләтнеке. Әле саклаасалар ярый. 1917 елларның архивларын өйрәнгәндә документларда кисеп алынган, сызылган урыннар күп иде. Илдә ниндидер куркыныч вакыйгалар башлана икән, беренче эш итеп "знаковый" кешеләрнең архивларын юк итәләр.

**БЕЛЕШМӘ:** Фәүзия Әүхади кызы Бәйрәмова – татар халкының күренекле сәясәтчесе, язучысы, җәмәгать эшлеклесе, тарих фәннәре кандидаты. "Иттифак"партиясе башлыгы. Төрки халыклар ассамблеясе рәисе урынбасары. Милли Мәҗлес рәисе (1994-1997, 2008). Татарстан Республикасы Югары Советы депутаты (1990-1995).



Фәкил Сафин һәм Вахит Имамов белән

**– Кайбер мөһим мәгълүматларны берничә җиргә тапшырып булмыймы? Ничек тә күчермәләр эшләп дию...**

– Милли китапханәгә чит илләрдән кайткан архивларны, шәхесләрнең беркем күрмәгән хатларын туплап бирдем. Гариф Солтан архивының бер өлешен, Гаяз Исхакый чыгарган журналларны. Кайбер әйберләрнең күчермәләрен үземә дә алып калдым. Тышлыкларын булса да төшердем. 30-40 шундый документ эшләп, үзеңдә сакларга була. Меңләгәнне алай итеп булмый. Шуңа Аллаһка тапшырам. Архивлар документның беренче экземплярын гына ала. Мин аларның икенче, өченче экземплярларын музейларга бирдем, кайберсе үземдә кала. Мәсәлән, Нурулла Гарифның шәхси музеена милли хәрәкәтнең күп әйберләрен тапшырдым. Монда юк итсәләр, анда саклаыр дигән өмет бар.

**– Туплаган белемегез, тапкан бөтен мәгълүматларыгыз шулай ук романнарыгызда, иҗатыгызда чагыла, ул үзе дә зур хәзинә.**

– Әйе, идеологиясе шул. Бигрәк тә соңгы 20 елда язылган тарихи романнарым, Магнитогорск турында булсын, Себергә сөрелгән татарлар турында булсын, "Хиҗрәт", "Гөләйза" – барысы да тарихи фактларга нигезләнеп язылган әсәрләр.

Бүләкләр, түләү турында сораган идең. Мин исемнәр, бүләкләр өчен эшләмим. Исемнәрем юк, моңа хәзер исем дә китми. Халык белә, халык ярата, шунысы җитә.

**– Исемнәр, премияләр алучыларга мөнәсәбәтегез нинди?**

– Кешесенә карап. Иҗаты бар икән, кабул итәм, шул кеше өчен сөенәм. Без Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗев, Нурихан Фәттах кебек язучылардан соң килгән буын. Аннан соң төшә-төшә Тукай премиясенең дәрәҗәсе төшеп бетте. Ул хәзер теләсә кемгә бирелә. Укып та булмый торган, милләткә каршы булган, иҗатлары йомшак кешеләр дә алды бу премияне. Мин болай бәялим: милләткә хезмәт итәме бу әсәр, милли идеологиясе бармы һәм әдәби осталыгы нинди дәрәҗәдә? Шул әйберләр юк икән, әллә кем булса да, ул бүләккә лаек түгел дип саныйм. Тукай премиясен әле дә алмаган шактый гына лаек кешеләр бар. Бәлки әле исән булсалар, аларга да чират җитәр.

**– Гади авыл кызына ораторлык осталыгы каян килә? Алган белем, журналистикада, телевидениедә эшләү тәҗрибәсеме бу, әллә ул сезнең нәселдә булган сыйфатмы?**

– Барысы да бардыр. Нәрсә әйтергә, ничек әйтергә – алдан уйлыйсың. Язганда да шулай. Чыгыш ясаганда әйтәсе фикереңне төгәл итеп җиткерү мөһим. Су булмасын. Биш минутлык чыгышка да минем башымда беренче җөмләдән башлап соңгы сүзгә кадәр сценарий язылган була. Халык алдына чыгу мәсьәләсенә бик җаваплы карыйм. Ислам дининең 1100 еллыгы уңаеннан 60 очрашу эшләдем. Киров өлкәсенә дә бардым, Марига да, Башкортстанга да чыгып киттем. Бөтен Россия буенча йөреп чыктым. Аның өчен ислам тарихын яхшылап яңадан өйрәндем. Ул сөйли торган темага керү дип атала. Беренче чиратта система булырга тиеш, аннары халыкның йөрәгенә үтеп керә



Айдар Хәлим белән

торган вакыйгаларны сөйләргә кирәк. Күп белгәнеңне күрсәтергә теләп, ботка ясарга ярамый. Сценарий була, хроникасы төзелә. Фәүзия чыкты да, каты итеп әйтте дә, халык кул чабып калды түгел. Мин һәр чыгышыма зур эшкә әзерләнгән кебек әзерләнәм.

**– Сөйләмегездә кайбер кешене хәтта куркыта торган сыйфат – ул холкыгызга хас катылыкмы? Әллә тарихны өйрәнгән саен барлыкка килгән әрнү, җан авазымы?**

– Бу – милләт язмышы өчен ачыну. Утта яндырылган татар хатыннары, сөргенгә сөрелгән татар ирләре турында күп беләм. Сахалинга кадәр барып җиттем. Каторгадагы татарларның, репрессия вакытында атып үтерелгән татар әбиләренең дәүләт архивындагы исемлеген алып кайттым. Чехов эзләре буенча йөрдем. Сөйләгәндә, әсәрләремне язганда алар барысы да күз алдыма килә. Аяк-кулларындагы богауларның чыңлауларына кадәр ишетәм. Син ул сүзне бик дөрес әйттең, әрнүем, эчтәге яну, халыкка үзенең тарихын аңлатырга тырышу, аны бәхетле итеп күрү теләге ярсыта һәм интонациядә чагылыш таба. Дин кешесе, мөслимә буларак та, ана кеше, тарихчы, язучы буларак та мин халыкның йөрәгенә мөрәҗәгать итәм. "Син шундый бөек кешенең баласы, онытма! Балаларыңны татарча өйрәт, милләтеңне, динеңне югалтма, оныкларыңа җиткер", – дип әйтәм. Белемем һәм үземнең дә шулай яшәвем миңа өстенлек бирә. Әгәр бер төрле сөйләп, икенче төрле яшәсәм, миңа ышанмаслар иде. Сатмадым да, сатылмадым да.

**– Күп кенә ирләр дә башкарып чыга алмаган эшкә алынуыгыз өчен үкенгән чаклар булдымы?**

– Үкенү булырга мөмкин түгел. Аннары, мин иңнәремә авыр йөк алам дип алынмадым. Бу юлга чыкканда 40 яшем дә тулмаган иде. Башта мемориал, халык фронты төзелде, аннан соң милли хәрәкәт барлыкка килде. Килешәм, башта ирләрдән күтәсең. Мин юләр хатын түгел, беркемнең дә кураләтә ут астына керәсе килми. Балаларым, гаиләм бар. Милләт өчен хәлиткеч вакытта беркемнең дошми калуы дөрес түгел. Ирләр ни өчен дәшми, чөнки алар бәйле. Анысын да аңларга кирәк. Артык дөрес әйтә башласа, ирләрне җәмгыятьтән читләштерәләр, кага башлыйлар, тилегә караган кебек карыйлар. Европада мәйданга чыгарга мөмкин, бездә ул яктан ирләргә аеруча авыр. Менә шушы дәшүче булмаганга мин алга чыгарга мәҗбүр булдым.

**– Сез әле ирләрне аклар юллар да табасыз...**

– Эзләргә, табарга тырышам. Үземнең халкым бит. Ирләр җәмгыятьтән аерылмас өчен дәшми калырга мәҗбүр. Болай алар акрын гына булса да, халык өчен күбрәк эшләп кала алалар. Разил Вәлиевне күпме таладылар бит, дәшмисең дип. Ул дәшмичә генә үз эшен эшләде.

**– Иң бәхетле чорыгыз дип кайсы елларны әйтә аласыз?**

– Бер караганда, әни булган кеше бала тапкан вакытын, бала үскән чакларны әйтергә тиештер бәлки. Анысы да бик кадерле. Әмма мин менә шушы бәйсезлек өчен көрәш еллары дияр идем. Без яңа Татарстанны тудыру башында тордык. 1990-91 еллар, депутатлыкка үтү, парламентта милләтне яклап сөйләү, милләтнең хәле авырая башлагач мәйданга ачлыкка чыгып яту. Нишләптер мин бу елларны бәхетле елларым дип әйтәм, чөнки анда үз фикереңне әйтергә, көрәшергә мөмкинлек бар иде.

**– Ике атна буе ач тору мөмкинме?**

– Әйе, 14 көн эчендә мин 17 килога ябыктым. Соңгы көннәрдә су да бармады, йота алмый башладым. Мин генә түгел, анда биш-алты язучы, тулаем егермеләп кеше катнашты. Үзем генә булсам, бәлки берничә ирешә алмаган булыр идем. Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтәм, миңа шундый мөмкинлек тудырды, тарихның мәйданына алгы рәткә мине чыгарды, бу бик зур мәртәбә.

**– Сезнең балалар Казандамы? Зөлфияме, Сөләйманмы чит илдә яшиләр дип күңелгә кереп калган.**

*Ахыры 13 биттә.*

# Фәүзия Бәйрәмова: "Сатмадым да, сатылмадым да"

*Ахыры. Башы 2-3 биттә.*

– Икесе дә Казанда, икесе дә тел буенча белгечләр, лингвистлар, филологлар. Балалар чит илдә белем алып кайтты, шуңа кайбер кеше шунда яшәп калганнар дип уйлый.

**– Ә оныклар?..**

– Оныклар да булыр, Аллаһ теләсә.

**– Фәүзия апа, үскән нигез-йортыгыз исәнме, анда ун туганнан берәрсе яшиме?**

– Өй буш тора, барыбыз да китеп беттек шул. Күрше авылда сеңлем яши, өйне алар карап тора.

**– Фәүзия апа, безгә Хөсәен абый турында да сөйләп алыгыз инде.**

– Хөсәен (Түбән Новгород өлкәсе Кызыл Октябрь районы Әтәр авылыннан) районда баш архитектор булып эшләгән кеше, төбәк тарихы белән бик кызыксына. 34 авылдан ДНК алып чит илдә тикшертте, халык кайдан килгән, нинди миграция үткән, шуларны өйрәнә. Мәчет каршында мәдрәсә бинасын теркәтте, ремонтларын эшлиләр. Хәзер мәдрәсәне ачар өчен анда укытучылар белән укучылар туплыйбыз.

Узган ел 28 ноябрьдә Казанда никах укыттык. Уйлап эшләнгән эш бу. Ирем ике ел ярым элек коронавирус белән авырып вафат булды. Берүзем калдым. Без Хөсәен белән алты елдан артык таныш. Минем кебек хатынкыз янында үзеннән дә көчле рухлы, белемле, иманлы, тормышны да, тарихны да белә торган, диндәге һәм иң мөһиме – мине аңлый торган ир кеше булырга тиеш. Кирәк чакта авып китмәскә иңен куярдай кеше кирәк. Читтән караганда, минем бу яшьтә яңа гаилә коруым бәлки сәер тоеладыр. Әмма бу ир эзләп кенә тормыш кору түгел, юлдаш, фикердәш, үзем кебек кешене табу ул. Минем кебек милләтне ярата торган кеше. Башта халык аңламас дип бераз уңайсызландым. Бигрәк тә алар ягында кеше мине белми бит, шуңа күрә без өч ай буе халык белән очрашулар уздырдык, халыкка тарих, дин турында сөйләдек. Заманында Пенза, Саратов өлкәсе, Мордовияне аркылыгабуйга гизеп өйрәндем. "Мишәр иле ", Мишәр йорты" дигән фәнни популяр очерклар яздым. Ә менә Түбән Новгородка барырга туры килмәде, алар үзләре язалар, миңа мохтаҗ түгелләр дип уйладым. Барып карасам, анда да көчләп чукындыру, репрессияләр темасы ачылмаган һәм бөтен татар фәнендә бер дә өйрәнелмәгән тема бар – милли холык. Мишәр менталитеты Казан татарыннан нәрсәсе белән аерыла? Бик кызыклы тема бит бу, хәзер мишәрләр арасында яшәп, шуны өйрәнәм. Монда һәр татар үзен хан итеп тоя, шулай киерелеп, кинәнеп яши. Моның яхшы ягы – ул беркемгә дә мохтаҗ түгел, мескен түгел, начар ягы – бу мишәр ханы үзеннән башка беркемне дә күрми һәм танымый!

**– Җиңүчене халык алкышлый, җиңелгәндә ялгыз калдырып китәргә дә мөмкин. Рәнҗетмиме бу?**

– Үз эшеңне яратып эшләсәң, рәнҗетми. Яратып эшләмәсәң, авырлык күрәсең, интегәсең. Себерләргә, Сахалинга да чыгып киттем, һәр авырлыкның уңай ягын таба идем. Мин сөенеп эшлим. Түбән Новгород якларына китүемне дә чираттагы сәфәрем дип кабул иттем. Бәлкем соңгы сәфәремдер, Аллаһ ничек кушкан анысын.

**Альбина ГАЙНУЛЛИНА**